| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

№ 323-р 11 июнь 2015 ел

2015 елда Нурлат муниципаль районы территориясендә куркыныч метеорологик күренешләрнең нәтиҗәләрен йомшарту чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә куркыныч метеорологик күренешләрнең нәтиҗәләрен йомшарту чаралары турында» 2003 елның 03 июлендәге 352 номерлы карары белән тиешле оператив һәм превентив чараларны үз вакытында оештыру һәм уздыру максатларында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Барлык милек рәвешләрендәге оешмалар җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан биналарның һәм корылмаларның тотрыклылыгын гамәлгә ашыру өчен милектәге биналарны һәм корылмаларны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм нормаларын, аларны тикшереп тору һәм тикшерү графигын үтәү эшен оештырырга;

- авария-торгызу һәм ремонт эшләрен башкару өчен билгеләнгән материаль ресурслар, янгын сүндерү чаралары резервларының, түбәнгерәк (нормалаштырылган) запасларның торышын, кичектергесез авария-торгызу эшләрен үткәрү очрагында инженерлык, юл-төзелеш һәм башка техниканың әзерлеген тикшерергә, тулыландырырга һәм тикшереп торырга.

2. Нурлат шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенә тәкъдим итәргә:

- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль өстәмә системасының җирле звеносы көчләренең һәм чараларының даими әзерлеген тәэмин итәргә;

- «СтройЭкоСервис» ЖЧҖ белән берлектә (килешү буенча) 2015 елның 15 июнендә аударылган агачларны җыештыру һәм метеорология күренешләренә бәйле гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү буенча тәүлек буе эшләүче бригада төзергә.

3. «Нурлат үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибына Нурлат муниципаль районы сәламәтлек саклау учреждениеләренең, гадәттән тыш хәл

характерын исәпкә алып, халыкка ашыгыч һәм квалификацияле медицина ярдәме күрсәтүгә әзерлеген тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан метеорология хәле турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка үз вакытында хәбәр итүне оештыруны Татарстан Республикасы буенча 125 нче янгын часте башлыгына тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин